Исполнительный комитет
Камаевского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан

423643,РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул.Дифгата Сирая д.29А

Татарстан Республикасы
Менделеев муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
башкарма комитеты

423643 , РТ, Менделеевск районы, Камай
авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

26 март 2025 ел №2

КАРАР

Хуҗасыз хайваннарны кайтару
тыела торган урыннарны билгеләү
турында һәм хуҗасыз хайваннарны
хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү
урыннарына кайтару турында карар
кабул итүгә вәкаләтле затлар
исемлеген билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге Уставы нигезендә. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге башлыгы Ахунҗанов Илнар Мөхәммәтнур улын хуҗаларыннан башка терлекләрне элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итәргә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Камай авылы махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларда урнаштырып халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru " Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге башлыгы И.М. Ахунҗанов

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советының
2025 елның 26 мартындагы 2 номерлы
карарына 1 кушымта

Камай авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеге

Хайваннарны приютта стерильләштерү , тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтми торган хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына ( тотылган ау урынына) кире кайтару тыела, әгәр мондый хайваннарны приютларда, һәм территориядән 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса:

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

- җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).

- белем бирү оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

- мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

- җәмәгать туклануы оешмалары, сәүдә объектлары янындагы территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектлары урнашкан урыннар.

- йорт хайваннарын йөртү өчен билгеләнгән урыннар.

- күпфатирлы йортларга якын территорияләр, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм алардан файдалану өчен билгеләнгән объектлар һәм бу территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары, моңа күпфатирлы йортларга якын территорияләргә юллар барлыкка китерүче автомобиль юллары да керә.

- Зиратлар һәм мемориаль зоналар.